КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 9 ноябрь г.Казань № 1001

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче; 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы; 2019 ел, 15 гыйнвар, 2 нче; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 833 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча 1 515,584 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 79 берәмлек итеп билгеләргә, шул исәптән:

аппаратта вазыйфаи окладлар буенча 21,203 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслана торган 1 берәмлек итеп;

аппаратта вазыйфаи окладлар буенча 460,131 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган 20 берәмлек итеп;

территориаль бүлекләрдә вазыйфаи окладлар буенча 1 034,250 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган 58 берәмлек итеп.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бурычлар

2.1. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге;

урамнан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм урамнан тыш транспорттан файдалану кагыйдәләре үтәлешенә федераль дәүләт контроле.»;

4.1 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге;»;

өченче – бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарны һәм аларның тагылмаларын (Россия Федерациясе Кораллы Көчләре һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) теркәү, шулай ук аларга дәүләт теркәү билгеләре бирү;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсендә теркәлгән үзйөрешле техникага әледән-әле дәүләт техник тикшерүләрен үткәрү;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыклары бирү;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тиешле органнар тарафыннан уку-укыту учреждениеләрен аккредитацияләү турындагы мәсьәләне карап тикшерү һәм аларга тракторчылар һәм үзйөрешле машиналар машинистларын әзерләү хокукына лицензияләр бирү өчен әлеге учреждениеләргә белем бирү процессының җиһазлар таләпләренә туры килүе һәм аның тәэмин ителеше турында мәҗбүри таныклыклар бирү;»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хуҗалар, дәүләт һәм башка органнар сораулары буенча күзәтү астындагы машиналарның һәм җайланмаларның техник торышын бәяләү һәм калган ресурсын билгеләү;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмауга карата күзәтү астындагы машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре хуҗаларының транспорт чарасы хуҗасын алмаштыруга бәйле теркәү гамәлләрен башкарганда транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү һәм үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышы өлкәсендә күзәтчелек итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бурычларын үтәвен тикшерүдә тоту (үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен техник тикшерүдән тыш);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу.».

2. Бу карарның 1 нче пункты гамәле 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин